Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге ТатЦИК ис.торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

20 октябрь, 2023 года № 6

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге ТатЦИК ис.торак пунктындагы гражданнар җыенының 2023 елның 20 октябрендәге йомгаклау беркетмәсе нигезендә карар кабул ителде:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 149 (йөз кырык тугыз).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 81 (сиксән бер).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 78 (җитмеш сигез).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 3 (өч).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2024 елда ТатЦИК исемендәге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарын, 80 яшькә җиткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- балалар мәйданчыгын төзү һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Шәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов